| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 23 май г.Казань № 392

Югары белем бирүче «Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе – белем бирү оешмасы тибын һәм аның исемен «Әлмәт сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе итеп үзгәртү турында

Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр һәм урта звено белгечләрен әзерләү программасының сыйфатын яхшырту максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының югары белем бирүче «Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе – белем бирү оешмасы (алга таба – Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты) тибын һәм аның исемен «Әлмәт сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – Әлмәт сәүдә-икътисад техникумы) итеп үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Әлмәт сәүдә-икътисад техникумын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институтында белем алучыларны аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институтында гамәлдә булган урта һөнәр белеме бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү шартларын һәм программаларын саклап, Әлмәт сәүдә-икътисад техникумына күчерергә;

30 көн эчендә:

Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институтының Әлмәт сәүдә-икътисад техникумына кирәк булмаган мөлкәте исемлеген, шулай ук аларны алга таба

файдалану турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

ел саен Әлмәт сәүдә-икътисад техникумы өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен расларга;

Әлмәт сәүдә-икътисад техникумында белем алучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

60 көн эчендә Әлмәт сәүдә-икътисад техникумы уставын эшләргә һәм расларга.

3. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән ел саен раслана торган урта һөнәр белеме белгечлекләре һәм мөлкәтне карап тоту нормативлары буенча финанс чыгымнары нормативлары һәм гамәлгә куючы йөкләмәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин